**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО**
**КОМИТЕТА**
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.04.2020 **Чирмешән авылы** **№170**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәтне**
**арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен**
**түләүдән азат итү шартлары турында**

Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 821-р номерлы күрсәтмәсен үтәү йөзеннән, **КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы милкендә булган муниципаль мөлкәтне (алга таба - муниципаль мөлкәт) арендалау килешмәләре буенча, тәэмин итәргә:

а) кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән авиаташулар, аэропорт эшчәнлеге, автопассажирлар йөртү, мәдәният, ял һәм күңел ачу, физкультура-сәламәтләндерү эшчәнлеге һәм спорт, туристик хезмәт күрсәтү, кунакханә бизнесы, җәмәгать туклануы, өстәмә белем бирү, дәүләтнеке булмаган белем бирү учреждениеләре, конференцияләр һәм күргәзмәләр оештыру, халыкка көнкүреш хезмәтләре күрсәтү (ремонт, юу, химчистка, чәчтарашханә һәм матурлык салоннары хезмәтләре күрсәтү) өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы арендаторлар - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мөрәҗәгать иткән көннән җиде эш көне эчендә, 2020 елның апрель - июнь айлары өчен Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы муниципаль казнасын тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләре) арендалау килешмәләре буенча аренда түләвеннән мондый арендаторларны азат итүне күздә тоткан өстәмә килешүләр төзү. Күрсәтелгән аренда түләүләрен түләүдән азат итү гамәлгә ашырыла, әгәр аренда килешүендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы казнасын тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир

кишәрлекләрен) арендага бирү каралган булса, аны күрсәтелгән эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен куллану максатларында һәм күрсәтелгән эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен тиешле мөлкәттән файдалануны раслаучы документлар булганда;

б) Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында арендаторлар - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен әлеге күрсәтмә үз көченә кергән көннән өч эш көне эчендә әлеге пунктның «а» пунктчасы нигезендә өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге турында мәгълүмат урнаштыру.

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимы кертелгән көнгә әлеге күрсәтмәнең 1 пунктындагы «а» пунктчасында каралган эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы муниципаль казнасын тәшкил иткән муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалау шартнамәләре буенча алдагы чор өчен аренда түләүләрен түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаган арендаторларга карата әлеге карар нигезендә күрсәтелгән аренда түләүләрен түләүдән азат итү башкарыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына муниципаль милекне һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен түләү буенча азат ителү биргәндә, әлеге күрсәтмәнең 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән нигезләмәләргә таянып эш итәргә тәкъдим итәргә.

**Чирмешән муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **И.Н. Шәйдуллин**